СОВЕТ СОСНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» март 2023 нче ел № 64

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының " Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру үткәрү һәм билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 20.07.2020 елгы, № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосна авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосна авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә Сосна авыл җирлегенең 27.11.2012 ел, №48 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.7 пунктында:

- 1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты кулланылырга мөмкин. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге Советы карарында гражданнар арасында сораштыруны билгеләү турында түбәндәгеләр билгеләнә:»;

- 6 пунктына тубэндэге эчтәлекне өстәргә:

«6) " Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтын кулланып гражданнар арасында сораштырулар уздырылган очракта, сораштыруда катнашучыларны ачыклау тәртибе.»;

1.2. 17.1 пунктындагы 2 абзацны "яисә муниципаль берәмлектә яшәүчеләр" сүзләре белән өстәргә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов